# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Теләче, Мамадыш һәм Балык Бистәсе муниципаль районнарының һәм алар составына керүче аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составына керүче "Әбде авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең "Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге һәм "Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**


"Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 12 (VIII өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Теләче муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
10 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | | |
|---|---|---|
| 12(48) - 22(49) | - | Арча муниципаль районы |
| 22(49) - 1(51а) | - | Саба муниципаль районы |
| 1(51а) - 2(52) | - | Кукмара муниципаль районы |
| 2(52) - 3(53) | - | Мамадыш муниципаль районы |
| 3(53) - 28(55) | - | Балык Бистәсе муниципаль районы |
| 28(55) - 12(48) | - | Питрәч муниципаль районы |

"Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлеге
составына керүче авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Әбде авыл җирлеге |
| 2 | Айдар авыл җирлеге |
| 3 | Алан авыл җирлеге |
| 4 | Баландыш авыл җирлеге |
| 5 | Олы Мәтәскә авыл җирлеге |
| 6 | Олы Мишә авыл җирлеге |
| 7 | Олы Нырсы авыл җирлеге |
| 8 | Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге |
| 9 | Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге |
| 10 | Иске Җөри авыл җирлеге |
| 11 | Теләче авыл җирлеге |
| 12 | Үзәк авыл җирлеге |
| 13 | Шәдке авыл җирлеге"; |

2) 2 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Теләче муниципаль районы Арча, Кукмара, Мамадыш, Балык Бистәсе, Саба һәм Питрәч муниципаль районнары белән чиктәш.";

б) өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"– Мамадыш, Балык Бистәсе һәм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Олы Саурыш авылыннан 3,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче (53 нче) тоташу ноктасыннан алып "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Теләче участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталы буйлап 540 м көнбатышка таба, 430 м төньякка таба, 880 м көнбатышка таба, алга таба шул ук юнәлештә 4 м һәм төньякка таба 4 м бу урманчылыктагы 39 нчы урман кварталы буйлап, шуннан соң 3,196 км "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесендәге 29 нчы урман кварталының көнбатыш почмагында урнашкан ноктага кадәр бара;";

г) егерме беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлеге чиге "Саба муниципаль районы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Кукмара, Саба

һәм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Әбде авылыннан 4,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 1 нче (51а) тотапу ноктасыннан алып көнбатышка таба "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 4, 3, 2 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, алга таба 1,46 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, бу инеш агымы буенча 560 м аска таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 530 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, бу инеш агымы буенча 1,0 км өскә таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 930 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 670 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 405 м көнчыгышка таба, 960 м көньяк-көнчыгышка таба, 3,6 км көньяк-көнбатышка таба, шуннан соң шул ук юнәлештә 610 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 330 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 160 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 260 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 940 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 45 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 780 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 710 м чокыр төбе буйлап Нысы елгасына кадәр бара, бу елга агымы буенча 85 м өскә таба бу елгага инеш кушылган җиргә кадәр уза, 190 м бу инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 265 м автомобиль юлы буйлап Ташлыяр авылына кадәр уза, әлеге авылны көньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап әйләнеп үтә, аннары төньяк-көнчыгышка таба 480 м автомобиль юлы буйлап бара, алга таба кибеп баручы инеш агымы буенча 110 м өскә таба, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,27 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Теләче – Мамадыш автомобиль юлын кисеп үтеп, "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 22 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр бара, шуннан соң 1,87 км көньяк-көнчыгышка таба бу урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 530 м бу урманчылыктагы 30 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, аннары 640 м көньяк-көнбатышка таба бу урманчылыктагы 29 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба бу урман кварталының төньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап 1,08 км көнбатышка таба, 740 м көньяк-көнбатышка таба һәм 340 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары бу урманчылыктагы 28 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,66 км көньяк-көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 625 м көньякка таба уза, шуннан соң 1,58 км көньяк-көнбатышка таба бу урманчылыктагы 36 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, аннары, инешләрне кисеп үтеп, шул ук юнәлештә бу урманчылыктагы 72 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,18 км һәм көнбатыш чиге буйлап 550 м көньякка таба уза, алга таба бу урманчылыктагы 74 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 395 м көньякка таба һәм 320 м көнбатышка таба "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Теләче участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш

почмагына кадәр бара, аннары бу урман кварталының төньяк чиге буйлап 550 м көнбатышка таба, 440 м төньякка таба һәм 900 м көнбатышка таба уза, алга таба 5,6 км төньяк юнәлештә, Саба муниципаль районының Олы Кибәче торак пунктыннан 2,5 км көнбатыштарак Теләче – Мамадыш автомобиль юлын кисеп үтеп, Нысы елгасына кадәр, аннары бу елга үзәне буенча агым буйлап аска таба Мишә елгасы белән кушылган урынга кадәр бара;";

д) утызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлеге чиге "Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 2 нче (52 нче) тоташу ноктасыннан алып уртак юнәлештә көньяк-көнбатышка таба "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 16, 15, 17, 20, 27, 26, 25, 24, 23 нче урман кварталлары чикләре буйлап бу урманчылыктагы 22 нче урман кварталының төньяк почмагына кадәр уза, шул ук юнәлештә бу урман кварталының төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап аның төньяк-көнбатыш почмагына кадәр 4 м калганчы бара, шуннан соң 22 нче урман кварталы буйлап 1,86 км көньяк-көнчыгышка таба, 520 м бу урманчылыктагы 30 нчы урман кварталы буйлап уза, аннары бу урманчылыктагы 29 нчы урман кварталы буйлап 640 м көньяк-көнбатышка таба, 1,06 км көнбатышка таба, 740 м көньяк-көнбатышка һәм 320 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң бу урманчылыктагы 28 нче урман кварталы буйлап 1,66 км көньяк-көнбатышка таба, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 630 м көньякка таба уза, аннары 1,58 км көньяк-көнбатышка таба бу урманчылыктагы 36 нчы урман кварталы буйлап, 2,18 км бу урманчылыктагы 72 нче урман кварталы буйлап уза, шуннан соң, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, бу урман кварталы буйлап 540 м көньякка таба бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 380 м бу урманчылыктагы 74 нче урман кварталы буйлап бара, аннары 325 м көнбатышка таба бу урман кварталы буйлап 3 нче (53 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.";

е) утыз беренче – утыз тугызынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

3) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Теләче муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
3 нче кушымта

## Теләче муниципаль районының "Әбде авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама "Әбде авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Әбде авыл җирлеге Олы Мишә авыл җирлеге, Кукмара, Мамадыш, Балык Бистәсе һәм Саба муниципаль районнары белән чиктәш.

## Теләче муниципаль районының "Әбде авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге

Әбде авыл җирлеге чиге Саба муниципаль районы белән чиктәш җирдә Әбде, Олы Мишә авыл җирлекләре һәм Саба муниципаль районы чикләре тоташкан урында Олы Саурыш авылыннан 2,55 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып Теләче муниципаль районы чиге буйлап Әбде авыл җирлеге, Кукмара һәм Саба муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Әбде авылыннан 4,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 1 нче (51а) тоташу ноктасына кадәр уза.

Әбде авыл җирлеге чиге Кукмара муниципаль районы белән чиктәш җирдә 1 нче (51а) тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгыш юнәлештә Теләче муниципаль районы чиге буйлап Әбде авыл җирлеге, Кукмара һәм Мамадыш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Әбде авылыннан 2,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 2 нче (52 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Әбде авыл җирлеге чиге Мамадыш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 2 нче (52 нче) тоташу ноктасыннан алып Теләче муниципаль районы чиге буйлап Әбде авыл җирлеге, Мамадыш һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Олы Саурыш авылыннан 3,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче (53 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Әбде авыл җирлеге чиге Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 3 нче (53 нче) тоташу ноктасыннан алып Теләче муниципаль районы чиге буйлап Әбде, Олы Мишә авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Олы Саурыш авылыннан 2,54 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Әбде авыл җирлеге чиге Олы Мишә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып 4 м көнбатышка таба "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Теләче участок урманчылыгындагы 39 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

4) 8 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Баландыш авыл җирлеге" сүзләрен "Әбде, Баландыш авыл җирлекләре" сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацта "2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче (54 нче) тоташу ноктасына" сүзләрен "2,55 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына" сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацта "17 нче (54 нче) тоташу ноктасыннан" сүзләрен "Әбде, Олы Мишә авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Олы Саурыш авылыннан 2,54 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасыннан" сүзләренә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Олы Мишә авыл җирлеге чиге Әбде авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып 4 м көнбатышка таба "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Теләче участок урманчылыгындагы 39 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.".

**3 статья**

"Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составына керүче "Албай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең "Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге һәм "Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.


**4 статья**

"Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 11 (III өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

## "Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 5 (52) - 70 (15) | - Кукмара муниципаль районы |
| 70 (15) - 74 (16) | - Удмурт Республикасы |
| 74 (16) - 75 (61) | - Алабуга муниципаль районы |
| 75 (61) - 73 (60) | - Түбән Кама муниципаль районы |
| 73 (60) - 52 (59) | - Чистай муниципаль районы |
| 52 (59) - 1 (53) | - Балык Бистәсе муниципаль районы |
| 1 (53) - 5 (52) | - Теләче муниципаль районы |

"Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Мамадыш шәһәре |
| 2 | Албай авыл җирлеге |
| 3 | Югары Ушма авыл җирлеге |
| 4 | Дегетле авыл җирлеге |
| 5 | Дүсмәт авыл җирлеге |
| 6 | Ишки авыл җирлеге |
| 7 | Катмыш авыл җирлеге |
| 8 | Көмешкүл авыл җирлеге |
| 9 | Келәүш авыл җирлеге |
| 10 | Красная Горка авыл җирлеге |
| 11 | Керәшен Пакшины авыл җирлеге |
| 12 | Көек-Ерыкса авыл җирлеге |
| 13 | Малмыж авыл җирлеге |
| 14 | Кече Кирмән авыл җирлеге |
| 15 | Түбән Ушма авыл җирлеге |
| 16 | Түбән Сон авыл җирлеге |
| 17 | Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге |
| 18 | Түбән Шүләңгер авыл җирлеге |
| 19 | Никифорово авыл җирлеге |
| 20 | Олыяз авыл җирлеге |
| 21 | Омар авыл җирлеге |
| 22 | Отарка авыл җирлеге |
| 23 | Рагозино авыл җирлеге |
| 24 | Сикәнәс авыл җирлеге |
| 25 | Соколка авыл җирлеге |
| 26 | Урта Кирмән авыл җирлеге |
| 27 | Сон авыл җирлеге |
| 28 | Тауиле авыл җирлеге |
| 29 | Уразбахты авыл җирлеге |
| 30 | Урманчы авыл җирлеге |
| 31 | Усали авыл җирлеге |
| 32 | Шәдче авыл җирлеге |

| | |
|---|---|
| 33 | Шəмəк авыл җирлеге |
| 34 | Яке авыл җирлеге"; |

2) 2 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Саба," сүзен төшереп калдырырга;

б) унҗиденче абзацта "Мамадыш, Кукмара муниципаль районнары һəм Теләче муниципаль районының Әбде аралаш полосалы кишəрлеге чикләре ялганышында" сүзләрен "Мамадыш, Кукмара һəм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында" сүзләренə алмаштырырга;

в) унсигезенче абзацны түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

"Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берəмлеге чиге "Теләче муниципаль районы" муниципаль берəмлеге белəн чиктəш җирдə 5 нче (52 нче) тоташу ноктасыннан алып уртак юнəлештə көньяк-көнбатышка таба "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дəүлəт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 16, 15, 17, 20, 27, 26, 25, 24, 23 нче урман кварталлары чикләре буйлап бу урманчылыктагы 22 нче урман кварталының төньяк почмагына кадəр уза, шул ук юнəлештə бу урман кварталының төньяк һəм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап аның төньяк-көнбатыш почмагына кадəр 4 м калганчы бара, шуннан соң 22 нче урман кварталы буйлап 1,86 км көньяк-көнчыгышка таба, бу урманчылыктагы 30 нчы урман кварталы буйлап 520 м уза, аннары бу урманчылыктагы 29 нчы урман кварталы буйлап 640 м көньяк-көнбатышка таба, 1,06 км көнбатышка таба, 740 м көньяк-көнбатышка һəм 320 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң бу урманчылыктагы 28 нче урман кварталы буйлап 1,66 км көньяк-көнбатышка таба, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 630 м көньякка таба бара, аннары бу урманчылыктагы 36 нчы урман кварталы буйлап 1,58 км көньяк-көнбатышка таба, бу урманчылыктагы 72 нче урман кварталы буйлап 2,18 км уза, шуннан соң, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, бу урман кварталы буйлап 540 м көньякка таба бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, бу урманчылыктагы 74 нче урман кварталы буйлап 380 м бара, аннары бу урман кварталы буйлап 325 м көнбатышка таба Мамадыш, Балык Бистəсе һəм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Югары Әрнəш авылыннан 5,835 км төньяк-көнбатышта урнашкан 1 нче (53 нче) тоташу ноктасына кадəр уза.";

г) унтугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

д) егерме беренче абзацта "600 м көньякка таба" сүзләрен "596 м көньякка таба" сүзләренə алмаштырырга;

3) 4 нче кушымтада:

а) икенче абзацта ", Саба" сүзен төшереп калдырырга;

б) алтынчы абзацта "Албай авыл җирлеге, Балык Бистәсе һәм Саба муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Югары Әрнәш авылыннан 5,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 1 нче (53 нче) тоташу ноктасына" сүзләрен "Албай авыл җирлеге, Балык Бистәсе һәм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Югары Әрнәш авылыннан 5,835 км төньяк-көнбатышта урнашкан 1 нче (53 нче) тоташу ноктасына" сүзләренә алмаштырырга;

в) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) сигезенче абзацта "2 нче (52 А) тоташу ноктасыннан" сүзләрен "1 нче (53 нче) тоташу ноктасыннан" сүзләренә алмаштырырга.

**5 статья**

"Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составына керүче "Шомарбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең "Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге һәм "Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**6 статья**

"Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Балык Бистәсе муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
- 10 - тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның
чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 52 (57) - 2 (56) | - Лаеш муниципаль районы |
| 2 (56) 14 (55) | - Питрәч муниципаль районы |
| 14 (55) -31 (53) | - Теләче муниципаль районы |
| 31 (53) -60 (59) | - Мамадыш муниципаль районы |
| 60 (59) -54 (58) | - Чистай муниципаль районы |
| 54 (58) 52 (57) | - Алексеевск муниципаль районы |

"Балык Бистәсе муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге составына керүче
шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы |
| 2 | Анатыш авыл җирлеге |
| 3 | Балыклы Чүкәй авыл җирлеге |
| 4 | Бәтке авыл җирлеге |
| 5 | Биектау авыл җирлеге |
| 6 | Олы Елга авыл җирлеге |
| 7 | Олы Кульга авыл җирлеге |
| 8 | Зур Мәшләк авыл җирлеге |
| 9 | Олы Әшнәк авыл җирлеге |
| 10 | Олы Солтан авыл җирлеге |
| 11 | Казак Чаллысы авыл җирлеге |
| 12 | Корноухово авыл җирлеге |
| 13 | Күгәрчен авыл җирлеге |
| 14 | Күки авыл җирлеге |
| 15 | Котлы Бөкәш авыл җирлеге |
| 16 | Масловка авыл җирлеге |
| 17 | Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге |
| 18 | Яңа Арыш авыл җирлеге |
| 19 | Полянка авыл җирлеге |
| 20 | Рус Әшнәге авыл җирлеге |
| 21 | Сорочьи Горы авыл җирлеге |
| 22 | Троицкий Урай авыл җирлеге |
| 23 | Уракчы авыл җирлеге |
| 24 | Шомарбаш авыл җирлеге |
| 25 | Югары Ырга авыл җирлеге |
| 26 | Шумбут авыл җирлеге |
| 27 | Шумково авыл җирлеге |
| 28 | Балтач авыл җирлеге"; |

2) 2 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Саба," сүзен төшереп калдырырга;

б) дүртенче – алтынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

в) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"– Мамадыш, Саба һәм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Шомарбаш авылыннан 4,046 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче (53 нче) тоташу ноктасыннан алып "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Теләче участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталы буйлап 540 м көнбатышка таба, 430 м төньякка таба, 880 м көнбатышка таба, аннары шул ук юнәлештә 4 м һәм төньякка таба 4 м бу урманчылыктагы 39 нчы урман кварталы буйлап, алга таба 3,196 км көньяк-көнбатыш юнәлештә "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесендәге 29 нчы урман кварталының көнбатыш почмагында урнашкан ноктага кадәр бара;";

г) егерме сигезенче абзацта "600 м көньякка таба" сүзләрен "596 м көньякка таба" сүзләренә алмаштырырга;

3) 26 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта ", Саба" сүзен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацта "Шомарбаш авыл җирлеге, Саба һәм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Шомарбаш авылыннан 4,5 км төньяк-көнбатышта "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Теләче участок урманчылыгындагы 39 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан 30 нчы (54 нче) тоташу ноктасына" сүзләрен "Шомарбаш авыл җирлеге, Мамадыш һәм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Шомарбаш авылыннан 4,046 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче (53 нче) тоташу ноктасына" сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

**7 статья**

"Саба муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Саба муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Саба муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
10 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| *21(49) - 1(50)* | - Арча муниципаль районы |
| *1(50) - 2(51)* | - Балтач муниципаль районы |
| *2(51) - 39(51а)* | - Кукмара муниципаль районы |
| *39(51а) - 21(49)* | - Теләче муниципаль районы |

"Саба муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге составына керүче
шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогы |
| 2 | Арташ авыл җирлеге |
| 3 | Олы Кибәче авыл җирлеге |
| 4 | Олы Нырты авыл җирлеге |
| 5 | Олы Шыңар авыл җирлеге |
| 6 | Югары Симет авыл җирлеге |
| 7 | Яулаштау авыл җирлеге |
| 8 | Эзмә авыл җирлеге |
| 9 | Иштуган авыл җирлеге |
| 10 | Килдебәк авыл җирлеге |
| 11 | Курсабаш авыл җирлеге |
| 12 | Мишә авыл җирлеге |
| 13 | Мичән авыл җирлеге |
| 14 | Түбән Шытсу авыл җирлеге |
| 15 | Сатыш авыл җирлеге |
| 16 | Иске Икшермә авыл җирлеге |
| 17 | Тимершык авыл җирлеге |
| 18 | Шәмәрдән авыл җирлеге |
| 19 | Шекше авыл җирлеге |
| 20 | Юлбат авыл җирлеге"; |

2) 2 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Мамадыш, Балык Бистәсе," сүзләрен төшереп калдырырга;

б) унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"– алга таба чик 4,2 км көньяк-көнчыгыш юнәлештә Кукмара, Саба һәм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында урнашкан 39 нчы (51а) тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) унтугызынчы – егерме алтынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) егерме җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Саба муниципаль районы" муниципаль берәмлеге чиге "Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы (51а) тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 4, 3, 2 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, алга таба 1,46 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, бу инеш агымы буенча 560 м аска таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 530 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, бу инеш агымы буенча 1,0 км өскә таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 930 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 670 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 405 м көнчыгышка таба, 960 м көньяк-көнчыгышка таба, 3,6 км көньяк-көнбатышка таба, шуннан соң шул ук юнәлештә 610 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 330 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 160 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 260 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 940 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 45 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 780 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 710 м чокыр төбе буйлап Нысы елгасына кадәр бара, бу елга агымы буенча 85 м өскә таба бу елгага инеш коя торган җиргә кадәр уза, 190 м бу инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 265 м автомобиль юлы буйлап Ташлыяр авылына кадәр уза, әлеге авылны көньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап әйләнеп үтә, аннары төньяк-көнчыгышка таба 480 м автомобиль юлы буйлап бара, алга таба кибеп баручы инеш агымы буенча 110 м өскә таба, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,27 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Теләче – Мамадыш автомобиль юлын кисеп үтеп, "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 22 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр бара, шуннан соң 1,87 км көньяк-көнчыгышка таба бу урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 530 м бу урманчылыктагы 30 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, аннары бу урманчылыктагы 29 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 640 м көньяк-көнбатышка таба уза, алга таба бу урман кварталының төньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап 1,08 км көнбатышка таба, 740 м көньяк-көнбатышка таба һәм 340 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары бу урманчылыктагы 28 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,66 км көньяк-көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 625 м көньякка таба уза, шуннан соң бу урманчылыктагы 36 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,58 км көньяк-көнбатышка таба бара, аннары, инешләрне кисеп үтеп, шул ук юнәлештә бу урманчылыктагы 72 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,18 км һәм көнбатыш чиге буйлап 550 м көньякка таба уза, алга таба бу урманчылыктагы 74 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 395 м көньякка таба һәм 320 м көнбатышка таба "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Теләче участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш почмагына кадәр бара, аннары бу урман

кварталының төньяк чиге буйлап 550 м көнбатышка таба, 440 м төньякка таба һәм 900 м көнбатышка таба уза, алга таба 5,6 км төньяк юнәлештә, Саба муниципаль районының Олы Кибәче торак пунктыннан 2,5 км көнбатыштарак Теләче – Мамадыш автомобиль юлын кисеп үтеп, Нысы елгасына кадәр, аннары бу елга үзәне буенча агым буйлап аска таба Мишә елгасы белән кушылган урынга кадәр бара;";

3) 5 нче кушымтада:

а) икенче абзацта ", Мамадыш, Балык Бистәсе һәм Теләче муниципаль районнары" сүзләрен "һәм Теләче муниципаль районы" сүзләренә алмаштырырга;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Олы Кибәче авыл җирлеге чиге Теләче муниципаль районы белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып Саба муниципаль районы чиге буйлап 42 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) җиденче һәм сигезенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

4) 6 нчы кушымтада:

а) дүртенче абзацта "39 нчы (52 нче) тоташу ноктасына" сүзләрен "39 нчы (51а) тоташу ноктасына" сүзләренә алмаштырырга;

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Олы Нырты авыл җирлеге чиге Теләче муниципаль районы белән чиктәш җирдә 39 нчы (51а) тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба Саба муниципаль районы чиге буйлап 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.".

**8 статья**

"Кукмара муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 нче кушымтасына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (IV өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) икенче абзацта "муниципаль районнары һәм Теләче муниципаль районының Әбде полоса аша кишәрлеге" сүзләрен "һәм Теләче муниципаль районнары" сүзләренә алмаштырырга;

2) унҗиденче абзацта "Кукмара, Саба муниципаль районнарының һәм Теләче муниципаль районының Нысы елгасы буендагы "Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе урман

массивының көнчыгыш почмагында урнашкан Әбде полоса аша кишәрлегенең чикләре кушылган җирдә" сүзләрен "Кукмара, Саба һәм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

3) унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Кукмара муниципаль районы" муниципаль берәмлеге чиге "Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 62 нче (51а) тоташу ноктасыннан алып Нысы елгасы агымы буйлап аска таба 3,0 км, аннары 2,1 км көнчыгыш юнәлештә 63 нче (52 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.".

**9 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов


ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 22 мае
№ 24-ТРЗ

«Теләче, Мамадыш һәм Балык Бистәсе муниципаль районнарының һәм алар составына керүче аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

# "Теләче муниципаль районы", "Мамадыш муниципаль районы" һәм "Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлекләре чикләре үзгәрешенең

## карта-схемасы




Шартлы билгеләр

районнар чиге

җирлекләрнең чикләре

торак пункт

Мамадыш муниципаль районының Албай авыл җирлегенең Теләче муниципаль районының Әбде авыл җирлеге территориясе составына кертелүче территориясе

Балык Бистәсе муниципаль районының Шомарбаш авыл җирлегенең Теләче муниципаль районының Әбде авыл җирлеге территориясе составына кертелүче территориясе